| | | |
|---|---|---|
| **ГЛАВНОЕ<br>АРХИВНОЕ УПРАВЛЕНИЕ<br>ПРИ КАБИНЕТЕ<br>МИНИСТРОВ<br>РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН<br>(ТАТГЛАВАРХИВ)** | | **ТАТАРСТАН<br>РЕСПУБЛИКАСЫ<br>МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ<br>КАРШЫНДАГЫ<br>БАШ АРХИВ ИДАРӘСЕ<br>(ТАТБАШАРХИВ)** |

БОЕРЫК

10.02.2016 Казан шәһәре № 013-од

**Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты каршындагы Баш архив идарәсенең дәүләт граждан хезмәткәрләренең вазыйфаи бурычларын үтәгәндә мәнфәгатьләр конфликтына китерә торган яисә китерүе мөмкин булган шәхси кызыксынуы барлыкка килү турында хәбәр итүләре тәртибен раслау хакында**

«Коррупциягә каршы көрәш турында» 2008 елның 25 декабрендәге №273-ФЗ Федераль закон, «Россия Федерациясенең аерым дәүләт вазыйфаларын, федераль дәүләт хезмәте вазыйфаларын биләүче затларның һәм бүтән затларның вазыйфаи бурычларын үтәгәндә мәнфәгатьләр конфликтына китерә торган яисә китерүе мөмкин булган шәхси кызыксынуы барлыкка килүе турында хәбәр итүләре тәртибе хакында һәм Россия Федерациясе Президентының кайбер актларына үзгәрешләр кертү турында» Россия Федерациясе Президентының 2015 елның 22 декабрендәге № 650 Указы нигезендә б о е р ы к б и р ә м:

1. Кушымта итеп бирелүче Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты каршындагы Баш архив идарәсенең дәүләт граждан хезмәткәрләренең вазыйфаи бурычларын үтәгәндә мәнфәгатьләр конфликтына китерә торган яисә китерүе мөмкин булган шәхси кызыксынуы барлыкка килү турында хәбәр итүләре тәртибен расларга (алга таба – Тәртип).

2. Коррупцион хокук бозуларны кисәтү өчен җаваплы затка (Сәлахова Е.Х.) түбәндәгеләрне тәэмин итәргә:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты каршындагы Баш архив идарәсен аппаратындагы дәүләт граждан хезмәткәрләрен, шулай ук хезмәт контрактлары төзегәндә гражданнарны да әлеге боерык белән таныштыруны;

Тәртипне Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты каршындагы Баш архив идарәсенең мәгълүмат стендында һәм «Интернет» мәгълүмат-

телекоммуникация челтәрендәге Идарәнең рәсми сайтындагы «Коррупциягә каршы тору» бүлегендә урнаштырыруны.

3. Әлеге боерыкның үтәлешен тикшереп торуны үземдә калдырам.

Башлык И. Х. Әюпова

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты каршындагы Баш архив идарәсенең 10.02.2016 г. № 013-од боерыгы белән расланды

**Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты каршындагы Баш архив идарәсенең дәүләт граждан хезмәткәрләренең вазыйфаи бурычларын үтәгәндә мәнфәгатьләр конфликтына китерә торган яисә китерүе мөмкин булган шәхси кызыксынуы барлыкка килү турында хәбәр итүләре**
**ТӘРТИБЕ**

1. Әлеге Тәртип Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты каршындагы Баш архив идарәсендә (алга таба – Идарә) Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәрләренең (алга таба – граждан хезмәткәрләре) Идарә башлыгы үзләренә карата эшкә яллаучы булганда аның вәкиленә дәүләт граждан хезмәткәрләренең вазыйфаи бурычларын үтәгәндә мәнфәгатьләр конфликтына китерә торган яисә китерүе мөмкин булган шәхси кызыксынуы барлыкка килү турында хәбәр итү процедурасын регламентлый.

2. Хәбәр итү вазыйфаи бурычларын үтәгәндә мәнфәгатьләр конфликтына китерә торган яисә китерүе мөмкин булган шәхси кызыксынуы барлыкка килү турында әлеге Тәртип кушымтасында китерелгән форма буенча граждан хезмәткәре тарафыннан язма рәвештә төзелә (алга таба – хәбәрнамә) һәм Идарә башлыгына җибәрелә.

3. Идарә башлыгы өч эш көне эчендә алдан карау өчен хәбәрнамәне коррупцион һәм бүтән хокук бозуларны профилактикалау эше өчен җаваплы затка (алга таба – җаваплы зат) җибәрә.

4. Хәбәрнамәне алдан карау барышында җаваплы зат хәбәрнамә җибәргән граждан хезмәткәреннән анда бәян ителгән хәлләр буенча аңлатмалар алырга, дәүләт хакимияте органнарына, бүтән дәүләт органнарына, җирле үзидарә органнарына һәм кызыксынучы оешмаларга билгеләнгән тәртиптә гарызнамәләр җибәрүне китереп чыгарырга хокуклы.

5. Алдан карау нәтиҗәләре буенча җаваплы зат дәлилләнгән бәяләмә әзерли. Алдан карау барышында алынган хәбәрнамә, бәяләмә һәм материаллар алынганнан соң җиде эш көне эчендә Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты каршындагы Баш архив идарәсенең Дәүләт граждан хезмәткәрләренең хезмәттәге тәртибенә карата таләпләрне үтәү һәм мәнфәгатьләр конфликтын җайга салу комиссиясенә (алга таба – Комиссия) тапшырыла.

6. Әлеге Тәртипнең 4 пунктында күрсәтелгән гарызнамәләр җибәрелгән очракта, хәбәрнамә, бәяләмә һәм материаллар җаваплы зат тарафыннан хәбәрнамә алынганнан соң 45 көн эчендә Комиссия рәисенә тапшырыла. Күрсәтелгән срок Комиссия рәисе тарафыннан 30 көннән дә артмаган чорга озайтылырга мөмкин.

7. Хәбәрнамә, бәяләмә һәм материаллар Комиссия тарафыннан Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты каршындагы Баш архив идарәсенең Дәүләт

граждан хезмәткәрләренең хезмәттәге тәртибенә карата таләпләрне үтәү һәм мәнфәгатьләр конфликтын җайга салу комиссиясе турында Идарә боерыгы белән расланган нигезләмә нигезендә карала.

**10.02.2016 г. № 013-од Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты каршындагы Баш архив идарәсенең дәүләт граждан хезмәткәрләренең вазыйфаи бурычларын үтәгәндә мәнфәгатьләр конфликтына китерә торган яисә китерүе мөмкин булган шәхси кызыксынуы барлыкка килү турында хәбәр итүләре тәртибенә**
**1 нче кушымта**

Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинеты
каршындагы Баш архив идарәсе
башлыгы

И. Х. Әюповага
__________________________________
_________________________________
(дәүләт хезмәткәренең Ф. Ис. Ат. ис., вазыйфасы, структур бүлекчә)

**Дәүләт вазыйфаларын үтәгәндә**

**мәнфәгатьләр конфликтына китерә торган яисә китерергә мөмкин булган шәхси кызыксыну барлыкка килү турында**
**хәбәрнамә**

Дәүләт вазыйфаларын үтәгәндә минем мәнфәгатьләр конфликтына китерә торган яисә китерергә мөмкин булган шәхси кызыксынуым барлыкка килү турында хәбәр итәм (кирәгенең астына сызарга).

Шәхси кызыксыну барлыкка килү өчен нигез булган хәлләр: ________________________________________________________________________________
________________________________________________________________________________

Үтәлүләре барышында шәхси кызыксыну йогынты ясый торган һәм йогынты ясарга мөмкин булган вазыйфаи бурычлар: ________________________________________________________________________________
________________________________________________________________________________

Мәнфәгатьләр конфликтын булдырмый калу яисә җайга салу буенча тәкъдим ителә торган чаралар:

______________________________________________________________________________

_____________________________________________________________________________

Әлеге хәбәрнамәне караганда Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты каршындагы Баш архив идарәсенең Дәүләт граждан хезмәткәрләренең хезмәттәге тәртибенә карата таләпләрне үтәү һәм мәнфәгатьләр конфликтын җайга салу комиссиясе утырышында шәхсән катнашырга ниятлим/нияләмим (кирәгенең астына сызарга).

"__" ____________ 20__ ел _____________________________ _______________________
(хәбәрнамә җибәргән затның имзасы (имзасы расшифровкасы)

**10.02.2016 ел № 013-од Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты каршындагы Баш архив идарәсенең дәүләт граждан хезмәткәрләренең вазыйфаи бурычларын үтәгәндә мәнфәгатьләр конфликтына китерә торган яисә китерүе мөмкин булган шәхси кызыксынуы барлыкка килү турында хәбәр итүләре тәртибенә**
**2 нче кушымта**

**Вазыйфаи бурычларын үтәгәндә мәнфәгатьләр конфликтына китерә торган яисә китерергә мөмкин булган шәхси кызыксыну барлыкка килү турындагы хәбәрнамәләрне теркәү**

**журналы**

| № т/с | Датасы | Хәбәрнамә биргән затның Ф.Ис.Ат.ис., вазыйфасы | Хәбәрнамә биргән затның имзасы | Теркәүченең Ф.Ис.Ат.ис. | Теркәүченең имзасы |
|---|---|---|---|---|---|
| | | | | | |
| | | | | | |
| | | | | | |